**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 5 июнендәге 1916 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 29 гыйнварындагы 244 номерлы «2026 елда «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) чыгым нормативларын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 25 февралендәге 541 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль бирем формалаштыру һәм муниципаль бирем үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы, 2025 елның 14 мартындагы 700 номерлы «“Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты” муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарлары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 29 гыйнварындагы 244 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 29 гыйнварындагы 244 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның  5 июнендәге
1916 номерлы карарына
кушымта

**«Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесенең 2026 елга эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) чыгым нормативлары**

| № т/б | Күрсәтелә торган хезмәтнең (эшнең) атамасы | Хезмәтнең (эшнең) эчтәлеге | | Чыгымнарның норматив күләме (сумнарда, елына) |
|---|---|---|---|---|
| | | күрсәткечнең атамасы | күрсәткеч билгесе | |
| 1 | Муниципаль милектәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү), 2026 елның 1 гыйнварына | Эшнең асылы | Җиһазларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү | 301 370 989 |
| 2 | Мәгълүмат ресурсларын һәм белешмәләр базасын алып бару | - | - | 27 813 380 |
| 3 | Программа белән тәэмин итү, инженерлык, исәпләү һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасы белән тәэмин итү, шул исәптән болыт технологияләре нигезендә дә | Телекоммуникация җиһазларының төре | Эшче станцияләр составыннан тыш кулланыла торган периферия һәм махсуслаштырылган җиһазлар | 14 617 658 |

________________________